**Республика Татарстан**
**ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**
ул. Куйбышева, д.31, с. Сарманово, 423350.
Тел: (85559) 2-44-97, Тел/факс 2-52-21
E-mail: sarmimkc@yandex.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ**
**МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ**
Куйбышев урамы, 31 йорт, Сарман авылы, 423350
Тел: (85559) 2-44-97,Тел/факс 2-52-21
E-mail: sarmimkc@yandex.ru

ОГРН 1101687000744 ИНН/КПП 1636006786/163601001 БИК 049205001

**«19» июля 2021 г.** **№** 303

# Каникул вакытларында профилактик чаралар һәм белем бирү учреждениеләрендә балалар травматизмын кисәтү

Белем бирү учреждениеләрендә ел дәвамында балаларның юл травматизмын кисәтү буенча системалы рәвештә эш алып барыла.

Һәр уку елында беренче сыйныф укучыларына ЮХИДИ органнары яктылыкны кире кайтаручы беләзекләр тапшыра. Бу уку елыда башлангыч сыйныф укучыларында алар – 100%, урта һәм өлкән сыйныфларда – 88% тәшкил итә. Шулай ук сыйныф сәгатьләрендә һәм ата-аналар җыелышларында ЮХИДИ хезмәткәрләре чыгышлар ясыйлар.

Укучылар белән уку елы дәвамында юл йөрү кагыйдәләре буенча чаралар уздырыла: “Йөрүче автобус”, “Куркынычсызлык әлифбасы”, “Юл билгеләре иленә сәяхәт” һәм башкалар.

Иң күренеп тора торган урында, шулай ук куркынычсызлык почмакларында юл хәрәкәте билгеләре булган стендлар эшләнелде. Белем бирү оешмаларының юл куркынычсызлыгы паспорты һәм «Йорт-Мәктәп-Йорт»балалар хәрәкәте имин маршрутлары схемалары яңартылып тора.

Үсеп килүче буын арасында юл-транспорт имгәнүләрен профилактикалау буенча белем бирү учреждениеләрендә түбәндәге эшләр башкарыла:

1. Укучыларга юл иминлеге буенча сыйныф сәгатьләре һәрдаим уздырылып тора, бигрәк тә яктылык кайтаручы элементларны дөрес куллану кирәклеге турында аңлатыла, түгәрәкләргә һәм спорт секцияләренә йөрүче балигъ булмаганнарга аерым игътибар бирелә.
2. “Фликерлар кирәк” исеме астында ата-аналар өчен консультацияләр.
3. ЮХИДИ инспекторлары белән очрашулар.
4. Юл йөрү билгеләре белән танышу – урамга экскурсия.
5. «Юлларда иминлек – безнең уртак эшебез» темасына гаилә рәсемнәре конкурсы.
6. Юл йөрү кагыйдәләре буенча стендлар яңартыла. Алар һәр мәктәптә дә бар.

7. ЮИД отрядлары эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. 19 мәктәптә һәм 4 филиалда алар үз көчләренә эшлиләр. 23 отрядта бу уку елында 127 укучы бар. Алар кечкенә сыйныф укучыларына юл йөрү кагыйдәләрен аңлаталар, балалар бакчаларында булалар, төрле бәйгеләрдә катнашалар.

8 Юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнү максатыннан, "Игътибар-балалар!» айлыгы (сентябрь), «Куркынычсыз зебра "акциясе (сентябрь) уза. Әлеге чараларны үткәрү барышында балаларның юлларда куркынычсызлыгы, киемнәрендә яки яктылык кайтаргыч элементларның булуы аңлатыла, яшь хәрәкәт инспекторларының чыгышлары тыңлана, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча видеороликлар күрсәтелә, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча дәресләр үткәрелә.

9. Шулай ук һәр сыйныфта дәресләр беткәч, 5 минутлык уздырыла. Анда укучыларга тагын бер кат юл йөрү кагыйдәләре аңлатыла.

Башкарылган эшкә карамастан, җитешсезлекләр дә бар. Агымдагы уку елында мәктәп укучылары катнашында юл-транспорт һәлакәте очрагы теркәлде. Юл-транспорт һәлакәтендә елда туган сыйныф укучысы катнашты. Әлеге очрак буенча сыйныф сәгатендә укучылар белән сөйләшенде, ата-аналар җыелышында, сыйныф җитәкчеләре киңәшмәсендә фикер алышынды.

Алда укучыларның җәйге каникуллары. Шушы уңайдан да төрле эшләр эшләнелә. Юл йөрү кагыйдәләре аңлатып, кул куйдыртыла. Әти-әниләр җыелышлары уздырыла.

**Нәтиҗәләр:** балалар юл-транспорт травматизмын кисәтү буенча эшне нәтиҗәле дип санарга мөмкин.

Мәгариф бүлеге җитәкчесе урынбасары: Г.А.Габидуллин